**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең Урсак урманчылыгы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**26 ноябрь, 2022 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 26 ноябрендә 10 сәгатьтә булган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән «Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Урсак урманчылыгы торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә караган түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

а) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу».

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 28 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 15, бу 53,57 % тәшкил итә. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 15 катнашучы тавыш бирде;

"КАРШЫ" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең Урсак урманчылыгы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. «Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Урсак урманчылыгы торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган

акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә караган түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу» – кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р.Сафина